**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен**
**татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(муниципаль тур, 2017-2018 уку елы) 7 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл - 100**

## I. Теоретик биремнәр (35 балл).

1. Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләрнең жанрын билгеләгез (20 балл):
*Н.Думави “Яшь ана”;*
*Һ.Такташ “Мокамай”;*
*Ш.Камал “Акчарлаклар”;*
*Г.Исхакый “Җан Баевич”;*
*Г.Тукай “Туган җиремә”.*

2. Әлеге билгеләмәләрдән портрет төшенчәсенә туры килгәнен сайлап алыгыз (8 балл):
*1) әсәрләрдә табигать күренешләренең бирелешен ачыклый торган теоретик төшенчә;*
*2) геройның тышкы кыяфәтенең бирелеше;*
*3) әсәрдәге автор фикерен сурәтләү;*
*4) әсәрдәге вакыйгаларның бара торган урынын сурәтләү.*

3. Ш.Камалның “Акчарлаклар” повестенда акчарлаклар образы кайсы теоретик төшенчәгә туры килә (7 балл):
*А) сезонлы эшчеләр;*
*Б) Символ;*
*В) Пейзаж.*

## II. Әдәби иҗатка караган биремнәр (45 балл).

1. Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повестенда Солтан язмышы ничек тәмамлана? (5 балл)
2. Солтан кайсы иптәшләре турында “алар бервакытта да минем күңелемнән чыкмыйлар” дип искә ала? (10 балл)
3. Г.Ибраһимовның “Кызыл чәчәкләр” повесте мисалында әсәр исеменең сюжет белән бәйләнешен билгеләп карагыз, автор ни өчен нәкъ шушы исемне сайлаган дип уйлыйсыз? (15 балл)
4. Ни өчен әсәр бүген дә актуальлеген югалтмаган дип уйлыйсыз? (15 балл)

## III. Иҗади бирем (20 балл).

1. Дуслык турында кечкенә генә хикәя языгыз.